**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы составына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы турында» 2016 елның 4 ноябрендәге ПУ-985 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1090 номерлы, 2017 елның 20 октябрендәге ПУ-915 номерлы, 2018 елның 14 маендагы ПУ-370 номерлы һәм 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан М.М. Сәмигуллинны, В.Н. Циоманы чыгарырга;

б) Совет составына кертергә:

Вәлиев Айрат Мәгъдүт улын – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе аеруча мөһим эшләрне тикшерү буенча өченче бүлеге җитәкчесен (килешү буенча);

Соколов Алексей Владимировичны – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры урынбасары – полиция башлыгын (килешү буенча);

Шинкарев Михаил Александровичны – Балыкчылык буенча федераль агентлыкның Урта Идел территориаль идарәсе Татарстан Республикасы буенча су биологик ресурсларына дәүләт контроле, күзәтчелек һәм аларны саклау бүлеге башлыгы урынбасарын (килешү буенча).

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 11 июль
№ ПУ-396